СОВЕТ МАЙДАНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
МӘЙДАН АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ

КАРАР

25.10.2023г.

с. Майдан

№ 35-191

Гражданнарның үзара салымын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Югары Ослан муниципаль районы Мәйдан авыл җирлегенең территориясенең бер өлешендә гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, «Мәйдан җирлеге Уставы нигезендә, Майдан авылының торак пунктының бер өлеше халкы төркеменең инициативасын карап чыгып.

Югары Ослан муниципаль районы
Мәйдан авыл җирлеге Советы
карар итте:

1. Югары Ослан муниципаль районының Мәйдан авылы җирлегендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча 2023 елның 7 ноябрендә гражданнар җыенын билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:

«2024 елда Югары Ослан муниципаль районының Мәйдан авылы җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, балигъ булган һәр кешедән 1000 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерү белән килешәсезме:

- Майдан авылына товарны җиткерүче хисабына билгеләнгән пунктка кадәр китетеп җиткерү белән Майдан авылы территориясенең бер өлешендә юлларны ремонтлау өчен вак таш сатып алу;

«ӘЙЕ» «ЮК»

3. Яшьләр урамы, 1 нче йорт янында 10.00 сәгатьтә Мәйдан авылы территориясенең бер өлешендә гражданнар җыенын үткәрергә.
Беренче май - 11.00 сәгатьтә 14 нче йорт янында,
Киров- 12.00 сәгатьтә 92 нче йорт янында.

3. Халык җыенын оештыручы итеп Мәйдан авыл җирлеге Башкарма комитетын билгеләргә.

4. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында, шулай ук җирлекнең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

5. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Совет рәисе,
Югары Ослан муниципаль районы
Мәйдан авыл җирлеге башлыгы В. В. Михеев